| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 май № 300

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт-хосусый партнерлык проектларына инвестицияләр җәлеп итүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эшче төркем төзү турында

Татарстан Республикасы территориясендә концессия һәм дәүләт-хосусый партнерлык механизмнарын кулланып тормышка ашырырга тәкъдим ителә торган проектларга инвестицияләр җәлеп итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт-хосусый партнерлык проектларына инвестицияләр җәлеп итүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эшче төркем төзергә.

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт-хосусый партнерлык проектларына инвестицияләр җәлеп итүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\300.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 май, 300 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә**
**дәүләт-хосусый партнерлык проектларына инвестицияләр җәлеп итүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эшче төркем турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт-хосусый партнерлык проектларына инвестицияләр җәлеп итүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – ведомствоара эшче төркем) перспективалы дәүләт-хосусый партнерлык проектларын формалаштыру һәм аларны тормышка ашыру йөзеннән инвестицияләр җәлеп итү өчен төзелгән орган булып тора.

2. Ведомствоара эшче төркем үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Перспективалы дәүләт-хосусый партнерлык проектларын формалаштыру һәм аларны тормышка ашыру өчен инвестицияләр җәлеп итү ведомствоара эшче төркемнең төп бурычы булып тора.

4. Ведомствоара эшче төркем әлеге бурычларны хәл иткәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, оешмалар, экспертлар белән билгеләнгән тәртиптә хезмәттәшлек итә.

5. Ведомствоара эшче төркем түбәндәге хокукларга ия:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан билгеләнгән тәртиптә ведомствоара эшче төркем компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча кирәкле материаллар соратып алырга;

ведомствоара эшче төркем компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча эш киңәшмәләре һәм очрашулар оештырырга һәм билгеләнгән тәртиптә үткәрергә;

ведомствоара эшче төркем эшчәнлегенә билгеләнгән тәртиптә фәнни-тикшеренү, мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләр белгечләрен җәлеп итәргә.

6. Ведомствоара эшче төркем составына рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь, шулай ук ведомствоара эшче төркем әгъзалары керә.

7. Ведомствоара эшче төркем рәисе:

ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

ведомствоара эшче төркем утырышларын үткәрү урынын һәм вакытын, шулай ук аларның көн тәртибен билгели;

ведомствоара эшче төркем эшчәнлеген оештыра һәм аның карарлары үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итә;

ведомствоара эшче төркем тарафыннан аның компетенциясенә караган аерым мәсьәләләрне карап тикшерү тәртибен билгели.

8. Ведомствоара эшче төркем рәисе вакытлыча булмаган чорда ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

9. Ведомствоара эшче төркем утырышлары кирәк булган очракта үткәрелә, ләкин кимендә кварталга бер тапкыр.

Ведомствоара эшче төркем утырышларын ведомствоара эшче төркем рәисе үткәрә.

Ведомствоара эшче төркем утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы санала.

Ведомствоара эшче төркем әгъзасы утырышта катнаша алмаса, ул карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үзенең фикерен язма рәвештә кертергә хокуклы.

10. Ведомствоара эшче төркем карарлары ведомствоара эшче төркем әгъзалары утырышында тавышларның күпчелеге белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны утырышта рәислек итүче һәм ведомствоара эшче төркемнең җаваплы секретаре имзалый. Тавыш бирү формасы – ачык. Тавышлар тигез булган очракта утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч була.

11. Ведомствоара эшче төркем эшчәнлегенең оештыру-техник тәэмин ителешен Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тормышка ашыра.

_______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 май, 300 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт-хосусый партнерлык проектларына инвестицияләр җәлеп итүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эшче төркем СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе, ведомствоара эшче төркем рәисе |
| Галиев Инсаф Мөшәррәф улы | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары, ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасары |
| Головин Сергей Валерьевич | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт-хосусый партнерлыкны үстерү бүлеге мөдире, ведомствоара эшче төркемнең җаваплы секретаре |
| Беляков Сергей Юрьевич | InfraONE инвестицион компаниясенең идарә итүче директоры (килешү буенча) |
| Гафаров Марат Ринат улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары |
| Демидов Сергей Анатольевич | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары |
| Еганян Альберт Суренович | InfraONE инвестицион компаниясенең Директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Рогожкин Максим Анатольевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенең дәүләт мөлкәте белән эш итү бүлеге мөдире |

| | |
|---|---|
| Сафиуллин Дамир Һарун улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Фәйзрәхманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Хәбипов Ришат Рәшит улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары |
| Хаҗиәхмәтов Булат Зөфәр улы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары |
| Чукин Артем Викторович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Шишмарева Елена Ивановна | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары. |

F:\KARAR\2016\300_2.doc